РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**исполнительный комитет**
**Большесалтыковского сельского поселения**

422831, Республика Татарстан,
Камско-Устьинский район,
с. Б.Салтыки, ул. 1 Мая,26А
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл жирлеге**
**башкарма комитеты**

422831, Татарстан Республикасы,
Кама Тамагы районы,
Олы Салтык авылы, 1 Май урамы, 26А
тел. (8437) 35-8-19
ИНН 1622004644

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«26» июль 2022 ел** **№ 11**

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 31 мартындагы 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының 31.03.2020 № 12 номерлы

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар максатларыннан һәм (яисә) муниципаль программаларга карамый торган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла».

1.2. 12 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының муниципаль программалар максатларына һәм (яисә) муниципаль программаларга карамый торган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына туры килүе».

1.3. 12 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташламаларга түләүчеләр тарафыннан бирелгән ташламаларга ихтыяҗ булу, ул ташламаларга хокуктан файдаланучы түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының 5 еллык чорга нисбәте белән характерлана».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче Р.М. Вафин